

ООО «Аксел»дә дүрт районнын - Темников, Теньгушево, Краснослободск һәм Ельник механизаторлары, механиклары, агрономнары, инженерлары һәм авыл хужалыгы житәкчеләре чәчүгә әзерлек буенча кинәшмәгә жыелдылар. Республикабызда шундый куст очрашулары үтә.

Аксел авылы мәдәният Йортында сойләшүнен теоретик олеше үтте. Анда яз башы чәчүенә техниканын әзерлеге буенча тәжрибә уртаклаштылар; унышлар һәм кимчелекләр аталды. Мордовия Республикасы авыл хужалыгы һәм азык-толек министры урынбасары А. И. Искандяров техниканын әзерлеге унышны зур иттереп үстерүдәге роле турында тагы бер тапкыр искәртте. - ...Яз башы чәчүенә тиешенчә әзерлек, - ди Альберт Ислям улы, - авыл хужалыгы елынын нигезе. Авырлыклар, гадәттәгечә, техника житмәүгә барып терәлә. Әгәр бездә бер комбаинга 500 гектар жирне эшкәртү норма итеп каралса, ә Европа илләрендә - бары 85 - 100 гектар гына. Шуннан техникабыз тиз эштән чыга, искерә. Уйлап карагыз, бүгенгә техникабызнын 50 проценты 10 яшьтән олы. Күбесенчә, ресурсын эшләгән инде. Тагы - тиешенчә сакламыйбыз, тиешенчә ремонтламыйбыз; яз башы чәчүенә дә тиешенчә әзерләмибез! Ә бит унышнын 35 проценты техниканын әзерлегеннән килә.

Мордовия агробизнес кадрлары белемен камилләштерү институты директоры, фән докторы М. Н. Чаткин фән яналыклары белән таныштырды һәм югары уныш алу очен механизаторлар әлегә кадәр игътибар итмәгән жирне соргәндә агротехник таләпләрне саклау, жирнен дымлылыгын да күздән югалтмаска тиешләр дип кинәш итте.

Очрашуда катнашучылар комбинированный культиваторлар, дисклы тырма, дискатор белән жир тирәнлеген билгеләүне үзләштерделәр. Аннары дорес эшкәрткәндә нинди үсентеләр булырга тиеш, ашлама кертү үзенчәлеге һәм башка чәчү һәм югары уныш алу очен кирәкле шартлар турында да сойләделәр.

Кинәшмәнен практик олеше тракторлар паркында үтте. Очрашуда район житәкчесе урынбасары В. П. Югалдина Темник районында чәчүгә әзерлек ничек баруы белән таныштырып үтте. Ул яровойлар чәчү күләмен әйтте: ООО «Тархановское» - 2305 га, ООО «Аксел» - 2354 га, ООО «Подсобное хозяйство» - 3200 га, сельхозколледж - 40 га, ООО «Агрофирма Ишейки» - 175 га, ООО «Агрофирма Кушки» - 405 га. 2017 елны валлы продукцияне 6,1 процентка арттырырлар дигән максатларын да ишеттерде. Яз башы чәчүенә 55 трактор, 12 сеялка-агрегатлар, 15 культиватор, 12 дискатор, 7 ашлама сиптерү машинасы әзерлеге турында әйтте. Орлыкларны да артыгы белән әзерләгәннәр, ди житәкче. Булган унышлары белән Темниклылар мул уртаклаштылар. Чәчүгә әзерләр

алар.
Нәтиҗәдә, гомерләрен иген үстерүгә багышлаган белгечләр, чәчүгә техниканың әзерлеген күрделәр, яналарын өйрәнделәр.

**Н.Хәлил**